ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.11.2024 Олы Кайбыч ав. № 412

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 30 маендагы 189 номерлы карары белән расланган «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» Федераль законның 31.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 333-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 30 маендагы 189 номерлы «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасын раслау турында» карары белән расланган «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль программа чаралары исемлеге

Программага Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмалар эшчәнлегенә ярдәм итүнең түбәндәге өстенлекле юнәлешләре керә:

- коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга финанс ярдәме;

-коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга мәгълүмати һәм консультатив ярдәм күрсәтү.

Коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга финанс ярдәменең өстенлекле юнәлешләре:

- Бөек Ватан сугышында катнашучыларны һәм инвалидларны социаль яклау

һәм аларга ярдәм итү;

- гражданнарның үз-үзләрен тотышының социаль куркыныч формаларын профилактикалау, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауда катнашу;

- җәмәгать тәртибен саклау өлкәсендәге ирекле эшчәнлек;

- хәйрия эшчәнлеге, шулай ук районның социаль, мәдәни, мәгариф һәм башка иҗтимагый әһәмиятле проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән хәйриячелек өлкәсендәге эшчәнлек;

- территорияләрне төзекләндерү.

Программа чаралары исемлеге программага кушымтада күрсәтелгән.».

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 20 февралендәге 60 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф. Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров